# КАРАР

**“08 ” ноябрь 2021 ел** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча районы Кәче авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә 2021 елның 08 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-Чулпан авылының юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларын вак таш белән тигезләү.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 177 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 91 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 84 кеше тавыш бирде;
“Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 7 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлегендә халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге Чулпан авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 75 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Чулпан авылының юл-урам челтәрендәге автомобиль юлларын вак таш белән тигезләү.

«ӘЙЕ» - 84 "КАРШЫ"-7

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендына: ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин урамы, 7а йорты адреслары буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Көче авыл җирлеге башлыгы Р.Д. Шаһиәхмәтов